Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Кәләй авыл җирлеге башлыгы

# КАРАРЫ

01 ноябрь 2019 ел N 1

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Кәләй авыл җирлегенең
Сабанчы авылында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм алардан
файдалану мәсьәләсе буенча
халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлегенең Сабанчы авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын 2019 елның 17 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Сабанчы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000,00 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү: Сабанчы авылы юлларын норматив хәлгә китерү, сметалар төзү һәм техник тикшерү уздыру өчен килешәсезме?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Халык җыенын түбәндәге адрес буенча урнашкан йорт янында уздырырга: Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Сабанчы авылы, Яббаров урамы, 1нче йорт.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Сабанчы авылы, Султанов урамы, 1А йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Кәләй
авыл җирлеге башлыгы В.Б. Воронин